КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 август г.Казань № 710

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 21 апрель, 312 нче , 2020 ел, 11 июль, 575 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү (03.03*);

төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү (03.03.01*);

һава, су, урамнан тыш, автомобиль транспортында, шул исәптән җиңел таксида, муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һәм шәһәр яны тимер юл транспортында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру (03.03.02*);

җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (03.03.03*);

юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә идарә итү (03.03.04*);

төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге (03.03.05*);

юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (03.03.06*).»;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (04.05*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан авыл хуҗалыгы белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.02);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы беләнн табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә функциясен тормышка ашырганда (01.06*);

Татарстан РеспубликасыТөзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән шәһәр төзелеше белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (01.05.01*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.04*);

---

* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы нигезендә кодны билгеләү.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән урман фондын куллану, саклау, яклау һәм урманнарны яңадан торгызу, урман үрчетү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу функциясен тормышка ашырганда (01.06.04*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү(01.03*);

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.07);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән бәяләрне (тарифларны) җайга салу функциясен тормышка ашырганда (01.08*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитеты белән туристлык өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.09*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестицион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү , инвестицион проектларны гамәлгә ашыруны комплекслы тәэмин итү функцияләрен тормышка ашырганда(01.10*);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.10*);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән килешүләр нигезендә:

муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын эшләгәндә һәм аны Татарстан Республикасы транспорт комплексы үсешенең стратегик юнәлешләренә экспертиза үткәргәннән соң килештергәндә;

«Юл хуҗалыгы һәм транспорт» бүлеге буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген бәяләү индикаторлары мониторингы регламентын һәм исәпләү методикасын эшләгәндә;

җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тоту, агымдагы һәм капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга акча чыгымнарының техник регламентларын һәм нормативларын эшләгәндә;

җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм муниципаль милеккә караган транспорт инфраструктурасы объектларын файдалануга алу буенча комиссияләрдә катнашканда;

мәгълүмати технологияләр кулланып, Татарстан Республикасы муниципаль районының транспорт комплексы үсеше дәрәҗәсе турында комплекслы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин иткәндә;

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән билгеләнгән мобилизацион биремнәрне һәм бурычларны үтәү мәсьәләләре буенча.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин